**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «17» апреленнән № 53-410

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-136 номерлы, 2022 елның 8 апрелендәге 20-161 номерлы, 2023 елның 26 маендагы 34-272 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 38-310 номерлы, 2024 елның 23 октябрендәге 49-379 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.1.пунктына түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Контроль объектлары турында белешмәләрне җыю, эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алу аларны хәвеф-хәтәр категориясенә кертү максатларында йә мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларын билгеләү контроль органы тарафыннан контрольдә тотыла торган затлар белән үзара хезмәттәшлексез (мәҗбүри профилактик визит кысаларында белешмәләрне җыюдан, эшкәртүдән, анализлаудан һәм исәпкә алудан тыш) гамәлгә ашырылырга тиеш. Контроль объектлары турында белешмәләрне җыюны, эшкәртүне, анализлауны һәм исәпкә алуны гамәлгә ашырганда аларны хәвеф-хәтәр категориясенә кертү максатларында йә контроль астындагы затларга мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларын билгеләү максатларында федераль законнарда каралмаган өстәмә бурычлар йөкләнә алмый.»;

1.2. Нигезләмәнең 3.4.пунктына түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Профилактик визит контрольдә тотылучы затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан профилактик әңгәмә рәвешендә яки видео-конференц-элемтә яисә «Инспектор» мобиль кушымтасы ярдәмендә үткәрелә.

3.4.2. Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы зат аның эшчәнлегенә

йә аның карамагындагы контроль объектларына карата куелган мәҗбүри таләпләр турында, аларның риск категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, риск категориясен, төрләрен, әчтәлеген һәм рискның тиешле категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында хәбәр итә, ә инспектор контроль объекты белән танышуны, тикшерү объектларын риск категориясенә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыюны гамәлгә ашыра һәм контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлү дәрәҗәсен бәяли.

Профилактик визит контроль органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотыла торган зат инициативасы буенча уздырыла.

Профилактика визитын уздыру йомгаклары буенча контроль объектына 2020 елның 31 июлендәге 249-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен ачык бәяләү бирелергә мөмкин.»;

1.3. Нигезләмәнең 4.1.1. пунктындагы өченче абзацында «тикшерелә торган затлар белән үзара хезмәттәшлек итмичә» сүзләреннән соң «(мәҗбүри профилактик визит кысаларында белешмәләрне җыюдан, эшкәртүдән, анализлаудан һәм исәпкә алудан тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.4. Нигезләмәнең 4.1.4 пунктында «тикшерелә торган затлар белән үзара хезмәттәшлек итмичә» сүзләреннән соң «(мәҗбүри профилактик визит кысаларында белешмәләрне җыюдан, эшкәртүдән, анализлаудан һәм исәпкә алудан тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.5. Нигезләмәнең 4.1.5. пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контроль чаралар үткәрүгә карата үзара хезмәттәшлек итмичә әлеге контроль чараны уздыру турында 2020 елның 31 июлендәге 249-ФЗ номерлы Федераль законның 64 статьясында каралган карар кабул итү таләп ителми.»;

1.6. Нигезләмәнең 4.1.11. пункты үз көчен югалткан дип танырга;

1.7. Нигезләмәнең 4.5.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.3. Документлар буенча тикшерү үткәрү срогы ун эш көненнән арта алмый. Контроль органы тарафыннан контрольдә тотыла торган затка документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны таләптә күрсәтелгән документларны Контроль органына тапшыру вакытына кадәр тапшыру таләпләре җибәрелгән вакытка, шулай ук контрольдә тотылучы зат тарафыннан тапшырылган документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында йә бу документлардагы белешмәләрнең Контроль (күзәтчелек) органындагы документлардагы белешмәләргә һәм (яисә) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында контрольдә тотылучы затка Контроль органы мәгълүматын җибәргән вакыттан алып чор һәм кирәкле язма аңлатмалар күрсәтелгән язма аңлатмаларны Контроль органга тапшырганчыга кадәр документлар буенча тикшерү үткәрү вакытын исәпләү туктатып тора.»;

1.8. Нигезләмәнең 4.1.10. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.9. Нигезләмәнең 4.9.3. пунктындагы икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

1.10. Нигезләмәнең 3 нче кушымтасының 2 нче искәрмәсен үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов